Ерактағы ак җилкәнәр

Оренбург шәһәре янәшәсендә бай тарихлы зур Каргалы авылы бар. Хәзерге рәсми язмаларда ул Татар Каргалысы дип атала. Соңгы елларда миңа ул авылда еш булырга туры килде. Анда күренекле татар зыялыларыннан Закир Рәмиев (Дәрдмәнд), Ризаэтдин Фәхретдин эзләре дә саклана.

Ул авыл элегрәк заманнарда мин үскән төбәкнең рухи-дини бер башкаласы булып торган. Безнең Бозаулык суы буе татар авыллары мулла-мәзиннәренең күпчелеге шуннан чыккан. Совет хакимияте чорында да Каргалыдан чыккан укытучылар ишле иде. Сугыштан соңгы елларда Бозаулык буе Иске Белогор авылында безне дә Каргалының бер кешесе укытты. Үз исеме Мөхәммәтне балалар теленә кертмәскә тырышып, ул үзенә «Салихов абый» дип эндәшүне генә хуп күрә иде.

Халык телендә бу авылның «Сакмар буе Каргалысы» дигән исеме дә бар. Чөнки ул Сакмар-су тамагына якын гына җирдә урнашкан. Әйе, татар дөньясына мәгълүм өч зур Каргалының берсе булган бу авылга карата халык телендә берничә төрле исем саклана. Еникиев, Терегулов морзаларның төп йорты саналган (элек Бәләбәй өязенә кергән) «Бәләбәй Каргалысы» белән Татарстанның Чистай шәһәре янәшәсендәге Каргалыдан аермалы буларак, Оренбург янәшәсендәгесенең тагын бер рәсми атамасы булуын да әйтеп үтик. XVIII-XIX йөзләргә караган язма документларда ул «Сәгыйдь бистәсе» (Сеитов посад) исеме белән дә йөргән. Ризаэтдин Фәхретдиннең Уфада яшәгәндә үк бу авылга багышлап «Сәгыйдь» исемле китап (1898 ел) язганлыгы һәм «Әхмәт бай» китабында (1911 ел) аерым бүлек багышлавы мәгълүм.

Каргалы элек Оренбург — Казан юлы өстендәге иң зур авылларның берсе булган. Хәзер дә әле ул Сакмар елгасы буйлап өч-дүрт чакрымга сузылып утыра. «Әхмәт бай» китабының «Каргалы шәһәре» бүлегендә Р. Фәхретдин XX йөз башы авылын болай тасвирлый: «Оренбургтан егерме чакрымнарда, Сакмар елгасының уң яры буйлап сузылган бер шәһәр булыр. Халык телендә ул Каргалы дип кенә йөртелә. (Бу исем аңа шәһәр уртасыннан Сакмарга агып төшүче Каргалы елгасына нисбәтле рәвештә бирелгән.) Аның «Сәгыйдь бистәсе» дигән атамасы да бар. Анда мөселманнар гына яши. Бу бистәне сәүдәгәр Сәгыйдь Хәялин нигезләгән, шунлыктан шәһәр аның исеме белән дә йөри. Җаек һәм Идел елгалары буйларында башка андый саф мөселман шәһәрләре юктыр. Шушы көндә Каргалыда ун



1749 елда имам Әбүбәкер Габделмөкмәнов белән Гатаулла Мөхәррәмов төзегән «Куш манаралы мәчет».

мәчет булып, күбесендә икешәр указлы мулла бар. Каргалының барлык әһалисе (халкы) чама белән унөч меңдер. Укымышлысы (хәлфә вә суфыйларны кертмичә) йөз ярым чамасы булачактыр. Каргалы шәһәрендә һәр гасырда үзенә күрә шөһрәтле галимнәр, аз булса да шагыйрь вә әдипләр яшәгән. Сәгыйдь бистәсен императрица Елизавета 1745 елда төзергә рөхсәт бирә... Шушы көнге Каргалыда әлегә почта вә телеграф юк, хастаханә дә юк. Моңа шәһәр исеме бирелүе башкалардан аеру ниятеннән эшләнгәндер. Оренбургта исә бу көндә йөз мең чамасы кеше яши, шуның дүрттән бер өлеше әһле ислам кешеседер», — ди галим.

Боларга өстәп шуны гына әйтик, патшабикә әмере чыкканчы ук бу авылга нигез салына башлый. Оренбург губернаторы И. И. Неплюев рөхсәте белән 1743 елда ук анда берничә йорт корыла. Димәк, Каргалы авылы хәзерге Оренбург шәһәре белән бер үк вакытта төзелә башлый. Ә кайбер галимнәр фикеренчә, ул җирдә элек-электән ерак бабаларыбыз яшәгән булырга тиеш. Чөнки ул безгә кардәш халыклы Урта Азия мәмләкәтләре белән Уфа, Казан төбәкләрен тоташтыручы сәүдә юлы өстендә утрак тормыш алып бару өчен иң җайлы урыннарның берсе.

Оренбург тарихчысы Сергей Попов хәбәр итүенчә, 1747 елда Каргалыда 173 йорт-каралты җитештерелгән, анда яшәүче ир-ат саны меңгә җиткән. Бу авылга зур сәүдәгә керешерлек бай мөлкәтле һәм әз-ким сәүдә тәжрибәсе туплаган кешеләрне генә алырга тырышканнар. Беренче күченеп утырган ике йөзләп сәүдәгәр башлыча Казан, Вятка, Сембер губерналарыннан китерелгән. Әлбәттә, алар арасында дин әһелләре дә ишле генә санала. Мәсәлән, Каргалының икенче ахуны, соңыннан илле ел чамасы Россиянең Европа һәм Себер өлеше мөселманнары мөфтие вазифасын үтәгән Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен әл-Борындыкый чыгышы белән Сембер губернасыннан булса кирәк. Һәр сәүдәгәр, һәр мулла йорт-кура һәм мал-туар тоту өчен үзе белән берничә хезмәткәрне алып килә алган. Аерым һөнәр осталарын чакырып китерү дә рөхсәт ителгән. Мондый мәсьәләләрне хәл итү авылның беренче старостасы Сәгыйдь Хәялинга йөкләтелгән була.

1780 еллар башында монда өч мәчет эшләгәнлеге мәгълүм. Аннары һәр ун-унбиш ел саен диярлек берәр мәчет салынган. Сакмар буендагы бишенче мәчетне булачак миллионер Хөсәеневләрнең бабасы Хөсәен бай салдырган, дип хәбәр итә Ризаэтдин хәзрәт. XVIII-XIX йөзләр аралыгында төзелгән кайбер таш мәчет биналары хәзер дә исән әле. Зәки мулла тырышлыгы белән төзелгән беренче таш мәчет 1775 елда ачылган. Элекке агач мәчет урынына яхшы кирпечтән өч катлы итеп 1883 елда төзелгән базар мәчете XIX йөзнең соңгы мәчете була. 1912 елгы зур янгыннан соң авылда тагын бер мәчет торгызыла.

Р. Фәхретдин үз китабының Каргалыга багышланган бүлегендә «бу шәһәр киләчәктә үз трамвае, телефон станциясе, хастаханәсе булган тагын да зуррак шәһәргә әверелер әле», дип язса да, ул өметләр өлешчә генә акланды. Без яшәгән гасырның утызынчы-кырыгынчы елларында биредә йортларга электр уты, радио кертелә башлый, телефон линиясе сузыла. Ә медицина

пункты (амбулатория) белән аптека унынчы елларда, унбиш авыруны дәвалауга исәпләнгән төбәк хастаханәсе исә 1961 елда ачыла. Совет хакимияте дәверендә элекке «шәһәр» үсми, киресенчә, йортлар саны бермә-бер, халык саны исә өчләтә-дүртләтә кими. (Хәзер авылда дүрт мең чамасы кеше яши.) Мондый «кимү»ләрнең сәбәпләре һәркемгә аңлашыладыр, ике-өч йорт хуҗасының берсе байлар исәбендә йөргән ич ул вакытта.

«Һәр мәчет хозурында ибтидаи (башлангыч) вә бәгъзеләрендә рөшди (жиде сыйныфлы) мәктәпләр ачыла», дип хәбәр итә Р. Фәхретдин. Әйе, авылда төзелеш барган елларда ук мәктәп-мәдрәсәләргә дә нигез салына. Тәүге мәдрәсә мөдәррисләре Каргалыга күченеп килгәнче үк дини уку йортларына җитәкчелек иткән абруйлы шәхесләр булалар. Шундый шәхесләр арасында Габдессәлам бине Уразмөхәммәт мулла беренче булып тора. 1746 елда Каргалыга күченеп килгәнче ул Казан артындагы Ташкичү авылы мәдрәсәсендә балалар укыткан. Каргалыга күчкәндә аңа 46 нчы яшь була. Белеме, тәжрибәсе дә җитү булган бу мулланы авыл сәүдәгәрләре махсус чакырып китергән булса кирәк. Килгәч тә ул монда беренче мәдрәсәне ачып җибәрә. Үзе белән ияртеп кайбер шәкертләрен дә алып килгәнлектән, хәлфә-мөгаллимнәргә кытлык кичерми. Тарихтан мәгълүм ки, патша хөкүмәте җәберләвенә түзә алмыйча баш күтәргән татар-башкортлар фетнәсен оештырган Батырша да шушы Габдессәлам ахун шәкертләреннән була. Оста янына оста, зыялы янына зыялы җыелыр дип әйтә бит халык. Шигъри җанлы мулла Габдессәлам артыннан ук диярлек Каргалыга Буа тарафыннан Вәлит мулла да килә. Вәлит бине Мөхәммәт әл-Әминне икенче мәхәллә каршындагы мәдрәсәгә баш итеп билгелиләр. Вәлит ишан хәзрәтләре белән Уразмөхәммәт ахунның (кыскача исеме Габдессәлам Урай) шигырь үрнәкләре безнең көннәргәчә сакланган. Аларның кайберләре «Татар поэзиясе антологиясе»ндә дә урын алганнар. Боларның мәдрәсәсенә әдәби һәм гыйльми ижат белән шөгыльләнүгә дәрте булган шәкертләр төрле тарафтан килә башлый. Оренбург губернасы Бөгелмә өязе Тимәш авылыннан килгән шәкерт Габдерәхим дә Каргалыда Вәлит ишан мәдрәсәсен үз итә. Укуын тәмәмлагач ул мәдрәсәдә калып, балаларга берничә ел белем бирә. Шушы җирлектә ул шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгарый буларак таныла, тәүге гыйльми эзләнүләрен шушында башлап җибәрә. Утыз Имәни белән бер үк чорда Каргалыда аның яшьтәше, каһарман язмышлы Салават Юлаев та белем ала. Билгеле, ул да олуг шагыйрьләр арасында үзенең шагыйрьлек көчен сынап карагандыр. Бу ике яшьтәшнең шәхес буларак җитешүләре һәм ижатларының чәчәк ату чоры, шөбһәсез, шушы Каргалы дәверенә туры киләдер. Габдерәхим Утыз Имәнинең Каргалы кызына өйләнүе, 1774 елда аларның кызы Бәдигыльҗәмал туганлыгы да мәгълүм.

Күпмедер вакыт Харәземдә һәм Казан артындагы Казаклар, Кышкар мәдрәсәләрендә шәкертләргә белем биреп, байтак тәжрибә туплаган шагыйрь һәм фикер иясе Ишнияз бине Ширнияз бине Ярмөхәммәт әл-Харәзми дә 1776 елда Каргалыга килеп төпләнә. Монда



1791 елда үлгән имам һәм шагыйрь Ишнияз бине Ширнияз әл-Харәзминең кабер ташы.

аны да мәдрәсә мөдәррисе итеп куялар. Ишнияз мулланың әдәби һәм гыйльми мирасы кулъязмалар хәлендә өлешчә Казан мирасханәләрендә саклана. Каргалы авылы зиратында тулы исем-атамасы язылган гадирәк кенә кабер ташы да бар әле. Аның төрки дөньяда мәшһүр булган «Ләйлә илә Мәҗнүн» поэмасы җирлегендә, шул исем белән аталган җыйнак эчтәлекле матур бер хикәя иҗат иткәнлеге, Каргалыда яшәү дәверендә 1780 елда «Гакаиде Болгарийә» (Болгарда дини ышанулар) фәлсәфи хезмәтен язганлыгы мәгълүм. Бу мәгърифәтче мулланың дини эчтәлекле дәреслек кулъязмаларының булуы да билгеле.

Бер авылда яшәгән Ишнияз бине Ширнияз остаз белән Утыз Имәнинең үзара аралашмаулары һич тә мөмкин түгел. Ләкин ул хакта әлегә тулы мәгълүмат юк. Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда Ишнияз мулланың күпчелек мирасын якташлары Үргәнеч каласына алып китәләр. Андагы мирас белән безнең галимнәр таныш түгел диярлек була. Утыз Имәнинең 1788 елда ишле гаиләсен алып Бохарага чыгып китүендә дә, бәлки, Ишнияз остазның йогынтысы булгандыр. Ләкин әлегә ул хакта мәгълүмәт юк шикелле. Ишнияз бине Ширнияз 1791 елда Каргалыда вафат була. Гаиләсе шунда торып кала. Варислары бүгенгә билгеле түгел. Каргалының беренче шагыйрьләреннән булган Габдессәлам Уразмөхәммәт (Урай) Каргалыга Утыз Имәни килгәнче үк, 1762 елда вафат булган. Вәлит мулла 1800 елда хаҗ сәфәренә китә һәм 1803 елда шунда гүр иясе була. Ләкин авылда аларның күпсанлы варислары, иҗатташ шәкертләре кала.

Каргалы халкының зыялы катламыннан чыккан, татар дөньясында күренекле эз калдырган шәхесләр дә ишле генә. Шулардан берничә исемгә генә тукталып үтик. Каргалы төбәгенә беркетелгән авыл муллаларына баш, ягъни ахун хәзрәтләре вазифасын да үтәгән Габдессәлам бине Уразмөхәммәтнең оныгы Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәламов исеме һәм иҗаты әдәбият сөючеләребезгә бик таныш. Ата-бабасы кебек мулла вазифасын үтәүдән бигрәк ул безгә классик шагыйрь Әбелмәних Каргалый буларак билгеле. Аның икенче тәхәллүс-кушаматы исә Сәгыйдь бистәсенә нисбәтле була: Хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди. Үз авылында мәдрәсә белемен үзләштергәннән соң, ул берникадәр вакыт Бохарада, Истанбулда укып йөргән. Шул үзәкләрдә иҗат иткән әдипләр белән аралашкан. Алар белән ярышып шигырь вә поэмаларын язган. Танылган әдәбият галиме М. Гайнуллин аны XIX йөз татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе дип атый. Р. Фәхретдин тә аның иҗатын бик югары бәяләгән: «Язылган шигырьләре һичбер җирдә вә гасырда йөз кызартачак түгел», дип әйткән.

Шагыйрь 1830 еллар урталарында, илле биш яшьләр чамасында, икенче мәртәбә хаҗга барган җирендә изге туфракта ятып кала.

Әбелмәних Каргалыйдан ундүрт-унбиш елга соңрак, 1794 елда туган Һибәтулла Сәедбаттал улы Салихов Сәгыйть бистәсе данын татар дөньясына тараткан өченче күренекле шагыйрь санала. Аның атасы Каргалыныкы, бабасы исә бу авылга Чистай өязеннән килгән кеше була. Һибәтулла туганда аның атасы Каргалыдан ерак булмаган Түбәнге Чебенле авылында мулла вазифасын



Имам һәм шагыйрь Һибәтулла Сәедбаттал улы Салиховның (1794-1867) кабер ташы.

үтәгән. Һибәтулла да Каргалы мәдрәсәсен тәмамлый. Мәдрәсәдә аның остазы шагыйрь Вәлиәтдин Бәгъдадый була. Һ. Салиховның мулла, мәдрәсә башлыгы һәм шагыйрь буларак дан казанган төп йорты — Каргалы. Бу авылның Сакмар очы зиратында аның кабер ташы сакланган. Ул 1867 елда вафат була. Кабер ташының арткы ягына «дүртенче сөйгән хатыны Бибимәхтүмәнең дә кабере» дигән сүзләр дә язылган. Димәк, бу кабер ташы янында икәүнең җәсәде ята. Каргалыда шагыйрь нәселе вәкилләре исән әле. Аларның кайберләре Салихов, бер ише Сәедбатталов фамилиясен йөртә. Күпчелеге укытучы һөнәрен сайлаган.

Шунысы да аерым әһәмияткә лаеклы, Каргалының өч зираты да, бер буй булып сузылып, кечерәк тау сыртына урнашканнар. Анда агач үстерелми. Тәбәнәгрәк һәйкәлташларны күмеп, дулкын-дулкын булып фәкать «чал сакаллы» кылган чайкалып утыра. Өч өлештән торган ул иске зират табигый таштан ясалган койма белән уратып алынган.

Әлеге олуг шагыйрьләрнең чордашлары һәм авылдашлары булган мәфти хәзрәтләрен дә искә алып китү зарур. Болар Россия мөселманнары арасында иң мәртәбәле вазифаны биләүче иң тәүге мөфтиләр Мөхәммәтҗан Хөсәенев, Габдессәлам бине Габдерәхим һәм Сәлимгәрәй Тәфкилевләр. Мөхәммәтҗан Каргалы төбәгенең беренче ахуны Мөхәммәт бине Гали әд-Дагыстаниның шәкерте була. Остазы вафатыннан соң байтак вакыт үзе дә ахун булып тора. Аңа шулай ук Урта Азия мөселман вәкилләре белән арадашлык итү вазифалары да йөкләнүе мәгълүм. Мөхәммәтҗан ахунның Россиягә әле буйсынмаган чиктәш казакъ илендә дә абруе зур була. Оренбург генерал-губернаторының Каргалы ахунын берничә мәртәбә Кече Жүз казакъ түрәләре янына дипломатик сөйләшүләр алып бару өчен җибәргәнлеге мәгълүм. Ахунның берничә айга сузылган шундый илчелек вазифаларын үтәүгә багышланган документаль язмалары 1939 елгы «Исторический архив» журналында да бәян ителә. Мөхәммәтҗан ахун Оренбург губернаторы барон Игельстром белән аеруча ышанычлы мөнәсәбәттә була. Булачак беренче мөфтигә бәйле рәсми язмалар СССР чорында Казакъстанда нәшер ителгән тарихи документларның 4 нче томында да урын алган («Собрание документов по истории колониальной политики царизма в Казахстане», 1939). Игельстром губернатор булганда Мөхәммәтҗанга Оренбург краеның беренче ахуны дәрәҗәсе бирелә.

Мөселман татар-башкортлар 1773-1774 елларда Е. Пугачев күтәрелешендә актив катнашалар. Шул ук елларда Төркия белән башланган сугыш Россия өчен уңышсыз тәмамлана. Кечек Кайнарҗада узган солых килешүенә дә мөселманнарның Россиядәге язмышына карата җитди тәкъдимнәр кертелә. Шушы вакыйгалардан соң патшабикә Екатерина илдәге сәясәтне беркадәр үзгәртергә ниятли, һәм 1778 елда патша хөкүмәте карары белән «Мөхәммәт дине җәмгыяте идарәсе» ачыла. Ш. Мәрҗани мөфтиятнең ачылу датасы дип 1778 елны күрсәтә, һәм аны Россия белән Төркия арасында шул ук елда төзелгән солыхка бәйли. Аның рәисе итеп тәжрибәле ахун Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен бине Мансур әл-Борындыкый билгеләнә. «Тәрҗемәи хәле сөйләнә торган зат, озын гомер сөреп, якынча илле ел мөфти булып, үз милкендәге авылда 1823 елда вафат», дип яза аның турында Ш. Мәрҗани. Бу идарә 1788-1789 еллар тирәсендә Уфага күчерелә. Исеме дә берникадәр үзгәртелә.

Мөхәммәтҗан мөфтинең ике кызы казакъ ханнары варисларына кияүгә бирелә. Фатыйма исемле кызының ире Җиһангир хан Бүкәев тиздән Россиянең мәшһүр генералы булып китә. Ул кардәш-ыру төрки халыкларның мәдәниятен үстерүгә билгеле бер өлеш керткән шәхес. Аның Саратов губернасындагы утарына татарның зыялы кешеләре дә килгәләп йөргән. Шул исәптән Казан галимнәреннән К. Фукс, Н. Катанов һәм башкалар белән аралашкан булуы билгеле. Җиһангир белән Фатыйманың бер кызы — Зөләйха — татар морзалары Тәфкилевләр килене. Аларның язмышы да Оренбург белән Каргалыга берникадәр бәйле. Элек-электән Тәфкилевләрнең зур җир биләмәләренең бер өлеше шул тирәләрдә була. Совет хакимияте дәверендә аларның Каргалы янәшәсендә генә булган төп утарында

Ленин исемендәге совхозның үзәге урнашкан иде.

Икенче мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим әл-Бөгелмәви чыгышы белән Бөгелмә өязенә кергән Габдерахман авылыннан. 1825-1838 елларда мөфти вазифасын башкара. Каргалыда укыганның соңында шунда ук мулла булып кала. Бохара ханлыгы илчелеге Россиягә килер алдыннан, 1799 елда беренче мөфти аны Оренбургка ахун итеп күчерә. Анда таш мәчет төзетү бурычын йөкли. Мәчет 1802 елда салынып бетә. Г. Ибраһимов укыган мәгълүм «Вәлия» мәдрәсәсе соңрак шул мәчет карамагында ачыла. Бу мулла шактый ук өлгер, үткер кеше булган ахрысы. Бохарадан һәм соңрак Хивадан килгән илчеләрне кабул иткәндә ул губернатор җәнапләре алдында да абруй казанып өлгерә. Ә инде император Александр I Оренбургка килгән 1824 елда Габдессәләм ахун мөфти кәнәфиен биләрлек дәрәҗәдә тырышлык, өлгерлек күрсәтә, һәм патша әмере белән 1825 елда мөфти итеп билгеләнә. Каргалы шагыйре Гомәр Мөхәммәт улының аңа багышланган ике зур шигъри әсәре бар. Бохара, Үргәнеч кунакларын кабул итү вакыйгалары «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» поэмасында бәян ителсә, Александр патшаны кабул итү күренешләре «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1837) дигән әсәрдә чагылыш тапкан. 1910 елларда Каргалы мулласы Гомәр Дәүләтъяров икенче мөфтинең шәхси кулъязмаларын мәчет чормасыннан табып ала һәм Ризаэтдин хәзрәткә тапшыра. Р. Фәхретдин аларны 1913 елгы «Шура» журналында бастырып чыгара.

Шундый ук дәрәҗәдәге тагын бер шәхесне — гаскәри хезмәттән мөфтилеккә тәгаенләнгән Сәлимгәрәй Шаһингәрәй улы Тәфкилевне дә өлешчә Каргалыга мөнәсәбәте булган кеше дип санарга хаклыбыз. Ул 1865-1885 елларда мөфти булып тора. Ә ерак бабасы исемен йөртүче соңгы морза — Котлымөхәммәт Батыргәрәй улы Тәфкилев, патша чорындагы дүрт чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты, үз җир биләмәләренең ике мең дисәтинәсен Мәхмүт бай Хөсәеневкә сатканда түбәндәге шартны куя: ул җирдән алынган керемнең бер өлеше, элеккечә үк, Каргалы мәчет-мәдрәсәләре файдасына бүлеп бирелергә тиеш, ди. Әлбәттә, андый кешеләрне Каргалы мәхәлләсе тарихыннан аерып карарга мөмкин түгелдер. Каргалы зиратында Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабернең саклануын да әйтеп үтү кирәктер. Урта зиратның иң алгы өлешендәге ул каберләр, борынгы төрбәләр рәвешенә китерелеп, биек таш койма белән уратып алынган. Төбәк тарихчысы М. Рәхимкулова ачыклавынча, беренче кабердә шушы төбәктә зур эшләр башкарган генерал Котлымөхәммәт Мәмәш улы Тәфкилевнең хатыны ята. Ул Тәфкилев заманында Урал-су буендагы Орск, Оренбург шәһәрләрен нигезләүдә катнашкан олуг бер шәхес. Каргалы «каласы»н нигезләшүдә дә өлеше булгандыр, мөгаен. Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабер ташы да сакланган. Ләкин икесе дә йөзтүбән капланып, ятылаш җиргә сеңгән булу сәбәпле, андагы язуларны элегрәк уку мөмкин түгел иде. Хәзер бер таш күтәртеп куелган. Таштагы язу өлешчә укыла. Ул кабергә Котлымөхәммәт морза-



Котлымөхәммәт Тәфкилевнең 1751 елда үлгән хатыны Хәдичә бикәнең кабер ташы.

ның җәмәгате Хәдичә бикәнең 1751 елда иңдерелгәнлеге бәян ителә, аңа 55 яшь булган. Тәфкилевләргә нисбәтле икенче ташның янындагы «1215 сәнә» язуы укыла. Ул сан хәзерге исәп белән 1800-1801 елларга туры килә. Ул кабердә Котлымөхәммәт Тәфкилевнең кызы ята дип уйланыла. Ул Оренбург атлы казаклары атаманы Тимәш морзага ярәшелгән була. Оренбург шәһәре үзәгендә (Совет урамы) Тимәш морзаның ике катлы затлы йорты хәзер дә бар әле. XIX гасыр ахырларында аны татарның мәшһүр бае, авылларда мәктәп-мәдрәсәләр тотуы белән дан казанган Гани Хөсәенев сатып алган була.

Элек Каргалыда табигый таштан нык итеп төзелгән торак йортлар, кибетләр, мәчетләр бик күп булган. Аларның бер өлеше бүген дә саклана әле. Авылда 1963 елдан кабат эшли башлаган зур таш мәчет бар. Элек ул парлы манаралы булган. Хәзер ул мәчет бер манаралы булса да, халык телендә һаман да әле «куш манаралы мәчет» буларак йөри. Соңгы елларда авылда тагын берничә таш мәчет торгызылды. Шуларның берсендә, авылның үрге очында урнашканында, 2006 елда икенче мәхәллә мәчете дә үз вазифасын үти башлады.



Л. Хәмидуллин Оренбург өлкәсе Каргалы авылында яңартып төзелгән мәчет янәшәсендә. Август, 2006 ел. Фото авторның шәхси архивыннан.

Фотолар, күрсәтелгәннән башка, шушы китаптан алынган: Искандеров Р., Искандеров А. Сеитов посад: Очерки по истории Оренбургской (Татарской) Каргалы. – Казань, 2005. – Приложение.

Лирон Хәмидуллин

РЕЗЮМЕ
В статье Л. Хамидуллина повествуется об истории д. Татар Каргалысы (Сеитов посад). Автор рассказывает о биографии, деятельности известных религиозных, общественных и литературных деятелей, родившихся в этой деревне.